| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ИСАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 ноябрь 2018 ел № 10

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Исәк авыл җирлегендә гражданнардан
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Уставы белән җирле референдумда (гражданнар җыенында) 2018 елның 19 ноябрендәге 9-6 номерлы карарны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адрес буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адрес буенча бастырып чыгарырга һәм ТР, Буа районы Исаково авылы, Мәктәп урамы, 27 нче йорт; ТР, Буа районы, Әлки авылы, Дуслык урамы, 14 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә кирәк.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

ТР Буа муниципаль районы Исәк авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе З.Р. Мөхәммәтҗанова

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Исәк авыл җирлеге
2018 елның 22 ноябреннән № 10
Башкарма комитет карары буенча
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Исәк авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында белдерү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, шулай ук имза астына тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүләрен гамәлгә ашыру юлы белән (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама буенча https://uslugi.tatarstan.ru/ башкарыла.

6. Касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый торган документлар булып тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Исәк авыл җирлеге
2018 елның 22 ноябреннән № 10
Башкарма комитет карары буенча
2 нче кушымта

ИЗВЕЩЕНИЕ (Хәбәрнамә) № _______________
Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге бюджетына үзара салым акчасын бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и ________________________________________________________
Адресы:
_________________________________________________________________
Нигез ____________________________________________________________
Сезгә _____________________кадәр ____________________чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр _____________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:_______________________________________________________
Алучы Банк БИК ________________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № ___________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Билгеләнгән түләү__________________________________________________________________________

Җитәкче __________________ _________________________________________
М.У. (имза) (имзаны тутырып язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - Өзү сызыгы- - - - - - - - - - - - - -

Извещение (Хәбәрнамә) № __________________
________сум күләмендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге бюджетына үзара салым акчасын бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.А.и. _________________________________________________________
Адресы:
____________________________________________________________________________
Алды «__» _______________ 20__ ел. _______________________________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Түләүчегә хәбәрнамә шәхсән тапшырылса, өзмә туплама тутырыла һәм башкарма комитетта кала.*